Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге составына керүче Ык Тамагы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022елның 17 декабрь №3

,

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 4 октябрендәге 20 номерлы карарына таянып, 2022 елның 17 декабре 10.00 сәг. узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. "Сез 2023 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум, 1-2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, Россия армиясендә вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын Ык Тамагы авылында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы?"

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

- вак таш сатып алу һәм китертү
- Вак ташны тигезләү буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү
- Кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Җәяүлеләр яр буеннан су буена төшү юлын төзекләндерү, территорияне төзекләндерү.

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 74 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 65 кеше

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**“ӘЙЕ"** 65 граждан тавыш бирде;

**"ЮК"** 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип санарга

"Сез 2023 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум, 1-2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, Россия армиясендә вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын Ык Тамагы авылында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы?" дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- вак таш сатып алу һәм китертү
- Вак ташны тигезләү буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү
- Кышкы чорда юлларны кардан чистарту

- Җәяүлеләр яр буеннан су буена төшү юлын төзекләндерү, территорияне төзекләндерү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И.Кәшәфетдинов